ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**29.11.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3794**

2024 елда Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансл\u044b кайнар ризык белән туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 07 сентябрендәге «2024-2026 елларга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында» 1099 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елга Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен уку чорында һәр көнне 66 сум 76 тиен күләмендә бушлай туклandыруны оештырырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклandыру өчен уку чорында һәр көнне Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2024 елга 9 сум 20 тиен итеп билгеләргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын үзләштерүче һәр укучыга уку чорында көн саен Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2024 елга 70 сум 34 тиен итеп түбәндәге категорияләргә билгеләргә:

- үз составында 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләдәге укучыларга;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Норлат урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендәге ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен «Норлат балалар йорты» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүчеләргә;

4. Җайлаштырылган уку-укыту программалары буенча белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәр укучыга һәр уку көненә Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2024 елга 105 сум 44 тиен итеп билгеләргә.

5. Махсус-хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән һәм махсус операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) яки инвалид булган гражданнар гаиләләреннән һәр укучыга һәр уку көненә Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2024 елга 105 сум 44 тиен итеп билгеләргә.

6. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку чорында кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны, 2024 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырырга.

7. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

8. Әлеге карар 2024 елның 9 гыйнварыннан үз көченә керә

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары- Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин